РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 08 » 06 2021 № 170

Аксубаево

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитетының «2020-2022 елларга Аксубай
муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау
буенча комплексы муниципаль программаны раслау
турында» 30.10.2019 ел, №756 карарына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Прокуратурасының «Федераль законнарның бозуларны бетерү турында» 15.05.2021 ел, №02-08-03, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты Күрсәтмәсен үтәү йөзеннән

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «2020-2022 елларга Аксубай муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалауның комплексы муниципаль программасын раслау турында» 30.10.2019 ел, №756 карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

карарның преамбуласын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Аксубай муниципаль районы территориясендә хокук бозуларны профилактикалау системасын үстерү һәм камилләштерү, җәмәгать тәртибен һәм җәмәгать иминлеген ныгыту, әлеге эшчәнлеккә иҗтимагый формированиеләрне һәм халыкны җәлеп итү, шулай ук «Татарстан Республикасында хокук бозуларны профилактикалау турында» 2017 елның 11 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Законны гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:»**

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aksubayevo.tatarstan.ru урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3.Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты карарының үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе: С.Ю.Зайцев